**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү комиссиясе турында» 2016 елның 26 декабрендәге ПУ-1229 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 10 мартындагы ПУ-209 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2017 елның 7 сентябрендәге ПУ-800 номерлы, 2018 елның 9 февралендәге ПУ-152 номерлы, 2018 елның 26 маендагы ПУ-392 номерлы, 2018 елның 13 декабрендәге ПУ-844 номерлы, 2019 елның 21 февралендәге ПУ-140 номерлы, 2019 елның 21 августындагы ПУ-478 номерлы, 2020 елның 18 февралендәге ПУ-100 номерлы, 2020 елның 4 мартындагы ПУ-136 номерлы, 2020 елның 12 декабрендәге ПУ-837 номерлы, 2021 елның 29 маендагы ПУ-412 номерлы, 2022 елның 7 июнендәге ПУ-399 номерлы, 2022 елның 12 сентябрендәге ПУ-638 номерлы, 2022 елның 26 декабрендәге 922 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 6 апрелендәге 213 номерлы һәм 2024 елның 4 декабрендәге 928 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан З.Р. Вәлиеваны, А.С. Груничевны, А.М. Пахомовны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Насыртдинов Олег Рәшит улын – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанслар һәм дәүләт милке белән эш итү идарәсе башлыгын;

Рассман Игорь Олеговичны – Татарстан Республикасы Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) генераль директоры вазыйфаларын башкаручыны (килешү буенча);

Терентьев Александр Михайловичны – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисен (килешү буенча);

в) Комиссия әгъзасы Р.В. Гайнетдиновның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2026 ел, 04 февраль
№ 99